РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ
09.11.2020

КАРАР
№13

Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 10 нчы номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республика Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 10 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең 11 498 сум күләмендә вазыйфаи окладын расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2020 елның 1 октябреннән башлап, яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/artash адресы буенча урнаштырырга.

Җирлек башлыгы А.Р.Аглямзянов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 2020 елның 9 ноябрендәге 13 номерлы карарына 1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаларның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 15 759 |
| Депутатлар | 11 498 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11 498 |